ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**25 декабрь 2019 ел** **Чистай шәһәре** **№ 709**

«Торак шартларын яхшыртуга
мохтаҗ табиб-белгечләргә торак
урыны наймга (арендага) түләү
буенча чыгымнарны компенсацияләү
тәртибен раслау хакында»

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында»гы 2019 елның 12 сентябрендәге 473 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында,Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ табибларга - торак урыны наймга (арендага) түләү буенча чыгымнарны компенсацияләү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Задворновага йөкләргә.

Башкарма
комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитеты тарафыннан
2019 елның 25 декабрендәге
709 номерлы карары белән
расланган

# ТОРАК ШАРТЛАРЫН ЯХШЫРТУГА МОХТАҖ ТАБИБ – БЕЛГЕЧЛӘРГӘ ТОРАК УРЫНЫ НАЙМГА (АРЕНДАГА) ТҮЛӘҮ БУЕНЧА ЧЫГЫМНАРНЫ КОМПЕНСАЦИЯЛӘҮ ТӘРТИБЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Әлеге тәртип Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында»гы 2019 елның 12 сентябрендәге 473 номерлы карары нигезендә, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ табиб – белгечләргә торак урыны наймга (арендага) түләү буенча чыгымнарны компенсацияләүнең бердәм тәртибен билгеләү һәм җирле бюджет акчаларының торак урыннарын наймга (арендага) түләүгә юнәлдерелгән чыгымнарын җайга салуны тәэмин итү һәм ул торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ табиб – белгечләргә (алга таба – текст буенча-табиб - белгеч) ярдәм күрсәтү максатларында (алга таба-программа буенча) эшләнде.

1.2. Торак урыны найм (аренда) бәясен түләү буенча чыгымнарны каплау хокукына программада күрсәтелгән таләпләргә туры килә торган табиб-белгечләр ия, ә атап әйткәндә:

- «Чистай үзәк район хастаханәсе» ГАУЗ белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы;
- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә 5 календарь ел эчендә яшәү урыны буенча теркәлмәгән;
- табиб - белгечнең һәм аның гаилә әгъзаларының милкендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә урнашкан торак урыннар булмавы.

## 2. Табиб-белгечләргә торак урынын наймга (арендага) түләү буенча чыгымнарны компенсацияләү тәртибе.

2.1 Торак урыннарга мохтаҗлар буларак билгеләнгән тәртиптә исәпкә куелган табиб-белгечләргә компенсация, Чистай муниципаль районында турыдан-туры эш урыны буенча бирелә.

2.2. Компенсация түләү турындагы мәсьәләне карау өчен, табиб-белгеч «Чистай үзәк район хастаханәсе» ГАУЗның баш табибы исеменә Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты алдында үтенеч белән мөрәҗәгать итү өчен, торак урыны наймга (арендага) түләү буенча чыгымнарга компенсация

бирү (алга таба - компенсация) турында гариза белән шәхсән мөрәҗәгать итә. Табиб-белгеч гаризага программада билгеләнгән документларны терки, атап әйткәндә:

- торак урыны наймы (аренда) шартнамәсе;
- программада катнашучы һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документлар күчермәләре (паспорт яки аны алмаштыручы башка документ);
- «Чистай үзәк район хастаханәсе» ГАУЗ белән хезмәт мөнәсәбәтләре булуын раслаучы документларның тиешле расланган күчермәләре (хезмәт килешүе, хезмәт кенәгәсендә тиешле язу);
- программада катнашучының гаилә мөнәсәбәтләрен раслаучы документлар күчермәләре (никах теркәү турында таныклык, аерылышу турында таныклык, бала (балалар) туу турында таныклык);
- йорт китабыннан өземтә яки финанс - шәхси счет, фатирлар карточкасы;
- программада катнашучы һәм аның гаилә әгъзалары били торган торак урыннан файдалану хокукын раслый торган документлар.

2.3. «Чистай үзәк район хастаханәсе» ГАУЗның баш табибы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетына табиб – белгеч һәм Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты арасында килешү төзү турында үтенеч белән табиб – белгеч биргән барлык документларны кушып мөрәҗәгать итә.

2.4. Мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты табиб – белгеч белән 1 нче кушымта нигезендә 1 календарь елга торак урыны наймга (арендага) түләү буенча чыгымнарны компенсацияләү турында килешү төзи.

2.5. Киләсе айдан башлап, килешү төзелгән көннән табиб – белгеч ай саен, 15 числога кадәр, Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлегенә ул һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыны наемына (аренда) түләүне раслаучы документлар бирә.

2.6. Торак урынны наймга (арендалага) түләү буенча чыгымнарны компенсацияләү өчен табиб-белгеч бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлегенә түбәндәге документларны бирә:

– Башкарма комитет белән табиб-белгеч арасында килешү;
- паспорт күчермәсе;
- торак урыны наймы (аренда) шартнамәсе;
- акча күчерү өчен счет ачу турында банк учреждениесе белән килешү;
- ачык счетка акча күчерү турында гариза.

2.6. «Чистай үзәк район хастаханәсе» ГАУЗның баш табибы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетына ай саен, айның 3 числосына кадәр, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты адресына үтенечләр әзерләнгән һәм компенсация түләү турында килешү төзелгән, «Чистай үзәк район хастаханәсе” ГАУЗ белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы табиб-белгечләр турында мәгълүмат бирә.

2.7. Узган ай ахырына «Чистай үзәк район хастаханәсе» ГАУЗ белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы табиб – белгечләр турында мәгълүматны раслаган очракта, табиб-белгеч документларын

тапшырганнан соң 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге компенсация түләүне банкта ачылган табиб-белгеч исәп-хисап счетына акча күчерү юлы белән тәэмин итә.

## 3.Табиб-белгечләргә торак урыны найм (аренда) белән бәйле чыгымнарны компенсацияләү күләмен исәпләү тәртибе.

3.1. Табиб-белгечләргә компенсация түләү күләмен исәпләү Чистай муниципаль районы башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан 2 нче кушымта нигезендә башкарыла.

3.2. Компенсация күләме торак урынын найм (аренда) шартнамәсе нигезендә, әмма «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» расланган муниципаль программасы буенча билгеләнгән 3500 сум күләмендәге максималь күрсәткечтән артмаска тиеш.

## 4. Табиб-белгечләргә торак урыны найм (аренда) белән бәйле чыгымнарны компенсацияләү күләмен үзгәртү һәм түләүне туктату тәртибе.

4.1. Табиб-белгечләргә компенсация түләү күләме, табиб-белгечне тәэмин итү өчен кирәк булган арендалана торган торак урыны мәйданы үзгәргән очракта, корректировкаланырга мөмкин, ләкин ул 3500 сум күләмендәге максималь күрсәткечтән артмаска тиеш.

4.2. Компенсация түләве түбәндәге очракларда туктатыла:

- подача заявления о снятии с учета;
- «Чистай үзәк район хастаханәсе» ГАУЗ белән хезмәт мөнәсәбәтләрен туктату;
- торак урыны сатып алу яки төзү өчен дәүләт хакимияте органыннан яисә җирле үзидарә органыннан билгеләнгән тәртиптә бюджет акчаларын алу;
- торак урыны наймы (аренда) шартнамәсенең гамәлдә булу срогы тәмамлану;
- башка муниципаль берәмлеккә чыгу.

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 25 декабрендәге
709 номерлы карарына
1 кушымта

# «2019-2021 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА МЕДИЦИНА КАДРЛАРЫН БЕРКЕТҮ ҺӘМ АЛАРНЫ ТОРАК БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ» ПРОГРАММАСЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ КЫСАЛАРЫНДА ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҺӘМ ТАБИБ-БЕЛГЕЧ АРАСЫНДА КОМПЕНСАЦИЯ ТҮЛӘҮ БУЕНЧА ___ КИЛЕШҮ»

Чистай шәһәре «____» __________20__ ел

Гамәлдәге Устав нигезендә эш итүче, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) исеменнән, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Хәсәнов Эдуард Рустамович, икенче Як _____________________________(Табиб-белгечнең Ф.И.О), дип атала торган Яклар исеменнән, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр.

## 1. КИЛЕШҮ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Әлеге Килешү Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында торак урыны наймга (арендага) түләү чыгымнарын компенсация рәвешендә табиб-белгечкә җирле бюджеттан акча түләү тәртибен һәм формасын билгели.

## 2. Якларның бурычлары

2.1. Башкарма комитет табиб-белгечкә ай саен, табиб-белгеч биргән документлар нигезендә, торак урыны наймы (арендасы) буенча чыгымнарны, әмма 3500 сумнан да артмаган сумманы компенсацияләргә йөкләнә.

2.2. Компенсация күләме торак урыны өчен түләү күләмен арттыруга бәйле рәвештә үзгәртелергә мөмкин.

2.3. Әлеге килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән торак урыны наймы (арендасы) буенча чыгымнарны компенсацияләү һәр айның _ _ _ числосыннан да соңга калмыйча башкарыла.

2.4. Табиб-белгеч ай саен Башкарма комитетның бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә «Чистай үзәк район хастаханәсе» ГАУЗ белән хезмәт мөнәсәбәтләре турында мәгълүматлар тапшырырга тиеш.

2.5. Компенсация түләүләре килү өчен, табиб-белгеч банк учреждениесендә үз исеменә исәп-хисап ача.

2.6. Табиб-белгеч торак урынын милеккә алган очракта компенсация түләүләре туктатыла.

2.7. Торак урынына найм шартнамәсе әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

## 3. Башка шартлар

3.1. Әлеге Килешү яклар тарафыннан имзаланган мизгелдән үз көченә керә һәм бер елга төзелә.

3.2. Якларның берсе берьяклы тәртиптә Килешүне өзү нияте булган очракта, бу хакта 30 календарь көннән дә соңга алмыйча, икенче Якка хәбәр итәргә тиеш.

3.3.Әлеге Килешү өч нөсхәдә төзелгән, аларның һәркайсы бер үк төрле юридик көчкә ия.

3.4. Кабул ителгән йөкләмәләрне үтәгәндә, Яклар гамәлдәге законнар нигезләмәләренә таяна һәм билгеләнгән компетенция чикләрендә эш итә.

3.5. Әлеге килешүгә үзгәрешләр яисә өстәмәләр кертү кирәк булган очракта, Яклар тарафыннан тиешле өстәмә килешүләр имзалана, алар әлеге килешүнең аерылгысыз өлешенә әверелә.

3.6 Әлеге килешү кысаларында барлыкка килә торган барлык бәхәсләр һәм каршылыклар сөйләшүләр юлы белән - судка кадәр тәртиптә җайга салынырга тиеш.

## 4. ЯКЛАРНЫҢ ЮРИДИК АДРЕСЛАРЫ ҺӘМ РЕКВИЗИТЛАРЫ

| | |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек<br>Башкарма комитеты<br>Юридик адрес:<br>422980, Чистай шәһәре,<br>Бебель ур, 129 | Табиб-белгечнең Ф.И.О.<br>Яшәү урыны буенча адресы: |
| ____________ Э.Р.Хәсәнов | _________________ Ф.И.О. |

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 25 декабрендәге
709 номерлы карарына
2 кушымта

# ТОРАК УРЫНЫН НАЙМ (АРЕНДАЛАУ) БЕЛӘН БӘЙЛЕ ТАБИБ-БЕЛГЕЧКӘ КОМПЕНСАЦИЯ КҮЛӘМЕН ИСӘПЛӘҮ ТӘРТИБЕ

1. Торак урынны наемга алу (арендалау) чыгымнарын компенсацияләү өчен бүлеп бирелгән җирле бюджет акчаларын куллануны тикшерүне көчәйтү максатларында, түләү тәртибе әлеге Тәртипнең 2 бүлеге белән җайга салына.
2. Компенсация күләме найм шартнамәсенең (аренданың) билгеле бер шартнамәсеннән һәм анда күрсәтелгән торак урынның (аренданың) чыгымнары һәм әлеге Тәртипнең 3.3 п. билгеләнгән максималь компенсацияләр күләменнән арта алмый.

3. Максималь компенсация күләме табиб-белгечне тәэмин итү өчен кирәкле торак урын мәйданыннан һәм торак урынның 1 кв. метрының иң чик хакыннан түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_{макс} = C_o \times S_{пол},$$ биредә,

$C_{макс}$ - максималь компенсация күләме (3500 сум);
$C_o$ – торак урыны мәйданының 1 кв. метрына найм (аренда) наемның иң чик бәясе;
$S_{пол}$ – табиб-белгеч тәэмин итү өчен кирәкле торак бинаның мәйданы.

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
_______________________ Э.Р. Хәсәнов
Раслыйм

“_____” ____________ 20___ елдан “____” ________ 20__ елга кадәр
табиб-белгечләргә торак урынын найм (арендалау) белән бәйле чыгымнарны компенсацияләү хакында белешмәләр

| Табиб-белгечнең Ф.И.О. Табиб-белгечнең гаризаларны исәпкә алу кенәгәсендә компенсация түләү турындагы гаризасын теркәү датасы | Торак комиссиясе карары | | Табиб-белгечнең һәм аның гаилә әгъза-ларының милкендәге торак урын мәйданы яисә соци-аль наем шартнамәсе буенча (кв.м) | Шарт-намә гамәлдә булу чоры | Яшәү урыны адресы | Аренда ки-лешүе ниге-зендә торак урынында яшәүче гаилә әгъзалары саны (табиб-белгечне дә кертеп) | Табиб-белгеч тәэмин итү өчен кирәкле торак урыны мәйданы | Россия Хезмәт ми-нистр-лыгы боерыгы ниге-зендә 1 кв. м. торак урынын наймга (аренда-лау) бәя-се (сум) | Торак урынны найм (аренда) өчен түләү күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую турында (датасы,беркетмә номеры, исәпкә кую өчен нигез). | Компенсация түләү турында (датсы,беркетмә номеры, компен-сация түләнә башлау датасы). | | | | | | | Найм (аренда) килешүе ниге-зендә бер айга | Компенсацияне түләү нормасын исәпләп чыгару буенча бер ай эчендә тәртипнең 3.1 пункты нигезендә | Хисап чорында барлыгы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| | | | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык
бүлеге башлыгы
________________ Г.Ф. Шаһиева

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
торак сәясәте бүлеге башлыгы
___________________ Х.Р. Нуруллина